Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр итү

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 06.08.2025 ел, № 55 карары нигезендә хокукый акт проекты: Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты (алга таба-проект) буенча иҗтимагый фикер алышулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:

- I өлеш. Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләрен куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибе.
- II өлеш. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;
- III өлеш. Шәһәр төзелеше регламентлары;
- Территориаль зоналар чикләре турында белешмәләр;
- Территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы;
- Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар.

Проект буенча иҗтимагый фикер алышулар үткәрү тәртибе һәм сроклары: 14.08.2025 елдан 12.09.2025 елга кадәр.

Җәмәгать фикер алышулары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ Федераль законы, Югары Ослан муниципаль берәмлеге Уставы, Югары Ослан районында җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм үткәрү турында Татарстан Республикасы Югары Ослан район Советының 04.06.2020 ел № 58-670 карары белән расланган Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар даирәсе: Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче, үзләренә карата әлеге проект әзерләнгән гражданнар, әлеге территория чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре, шулай ук күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

Иҗтимагый фикер алышулар уздырыла торган территория: Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Печищи авыл җирлеге.

Иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы: 14.08.2025 елдан башлап түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында:

- Югары Ослан авылы, Чехов ур., 32 йорт, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яшьләр-яшүсмерләр клубы бинасында;
- Печищи авылы торак пунктында, Декабристлар ур., 35а йорт, Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында;
- Захваткино авылы, Оконишников ур., 10 нчы йорт капкасында.

Проект экспозициясен үткәрү сроклары: 14.08.2025 елдан 12.09.2025 елга кадәр.

Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: дүш. - җомга 09-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр.
Җәмәгать фикер алышуларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен кертү тәртибе, сроклары һәм формасы: экспозицияне үткәрүнең бөтен чоры дәвамында Югары Ослан районының рәсми сайтында http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/, «Документлар»-«Шәһәр төзелеше»-«Иҗтимагый фикер алышулар» (14.08.2025 елдан 12.09.2025 елга кадәр) вкладкасында идентификация узган иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:
1) Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты аша: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru;
2) язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә - Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге адресына түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 32, тел: 8(84379) 2-16-59;
3) Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 32, тел: 8(84379) 2-16-59 адресы буенча иҗтимагый фикер алышуларда каралырга тиешле проект буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналына язу юлы белән.
Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә мондый проект урнаштырылачак һәм кулланып җәмәгать фикер алышулары үткәреләчәк мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: Югары Ослан муниципаль районының торак пунктлары исемлеге рәсми сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Әлеге хәбәрнамәне бастырып чыгарырга: 07.08.2025 елдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А. Ахметшин

Мәгълүмат стендларында иҗтимагый фикер алышулар башлану турында
хәбәр итү урнаштыру турында
Акт

Дата: 07.08.2025 ел

Әлеге акт Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 2025 елның 6 августындагы 55 номерлы карары нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча билгеләнгән иҗтимагый фикер алышулар башлану турындагы хәбәрнамәнең урнаштырылуын раслый.

Түбәндәге адреслар буенча урнашкан түбәндәге мәгълүмат стендларында:
- Югары Ослан авылы, Чехов ур., 32 йорт, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яшьләр-яшүсмерләр клубы бинасында - 10.00 сәгатьтән;
- Печищи авылы торак пунктында, Декабристлар ур., 35а йортында, Печищи авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында-11.00 сәг.
- Захваткино авылы, Оконишников ур., 10 йорт капкасында - 12.00 сәг.

Актка Печищи авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча текст һәм график материаллар кушымта итеп бирелә.

Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы
архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече Нуруллина Ф.Х.